СОВЕТ
СЕЛО-УБЕЙСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Улица Мира, дом 40, село Новый Убей,
Дрожжановский район 422464

Тынычлык урамы, 40 нче йорт, Яна Уби
авылы, Чүпрәле районы 422464

Тел.: (84375) 3-55-35, 3-55-36, e-mail: Subey.Drz@tatar.ru,
www. subey -drogganoe.tatarstan.ru

---

с. Новый Убей

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабрь 2022 ел №29/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Үби авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 4 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Үби авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Үби авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Үби авыл җирлеге Советының 06.06.2022 № 17/1 карары белән расланган нигезләмәгә, **8 статьяның 9 пунктының 3** абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне (бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү операцияләрен, бердәм салым түләүгә бәйле операцияләрне, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм Россия Федерациясе законнары белән мәҗбүри түләүләргә карата каралган аванс түләүләренә бәйле операцияләрне, хокукта каралган акчалата залогка бәйле операцияләрне планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра Евразия икътисадый берлеге һәм таможня җайга салу турында Россия Федерациясе законнары);».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы

Чүпрәле муниципаль районының Үби авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының авыл җирлеге рәсми сайтында һәм махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Чүпрәле муниципаль районы
Үби авыл җирлеге Башлыгы: А.П. Ярухин